МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.07.2017 № 347-пр

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 2 июлендә теркәлде, № 3989

2017 елның 2 июлендә
Татарстан Республикасының Зәй
районында булган автоһәлакәт
нәтиҗәсендә зыян күргән
гражданнарга бер мәртәбә матди
ярдәм күрсәтү тәртибе турында

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 02 июлендәге 455 номерлы карары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымтада бирелгән 2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.
2. Бу боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Н.В. Бутаеваны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
02.07.2017 № 347 боерыгы
белән расланды

# 2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү тәртибе

1. Бу Тәртип 2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм түләүнең шартларын билгели (алга таба – Тәртип).

2. Бер мәртәбә матди ярдәм алу хокукына түбәндәгеләр ия:

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданарның гаилә әгъзалары (алга таба – һәлак булучының (үлученең) гаилә әгъзалары). Һәлак булган (үлгән) гражданинның гаилә әгъзаларына ире (хатыны), ата-анасы, балалары, вафат булу көненә һәлак булучының (үлученең) иждивениесендә торган затлар керә;

сәламәтлегенә зыян килгән гражданнар (алга таба – зыян күрүче гражданнар).

3. Бер мәртәбә матди ярдәм түләү турында гариза Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) яисә аның социаль яклау буенча территориаль органына (алга таба – социаль яклау органы) гражданин яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән тапшырыла. Гражданин һәлак булган (үлгән) очракта гариза һәлак булучының (үлученең) һәр гаилә әгъзасы яисә, шушы Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны тапшырып, аларның ышанычлы заты тарафыннан тапшырыла.

4. Һәлак булучының (үлученең) гаилә әгъзасы яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат бер мәртәбә матди ярдәм түләү турында гаризаны шушы Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы рәвеш буенча тапшыра.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

һәлак булучының (үлученең) вафат булуы турында таныклык күчермәсе;

һәлак булучы (үлүче) белән туганлык мөнәсәбәтләрен таныклый торган документларның күчермәләре;

билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе тарафыннан бирелгән, гаилә әгъзасын зыян күрүче дип тану турында документ күчермәсе;

һәлак булучының (үлученең) иждивениесендә тору фактын раслый торган документларның күчермәләре, - һәлак булучының (үлученең) иждивениесендә торган очракта;

кредит оешмасында ачылган лицевой счет реквизитлары белән документ күчермәсе;

әгәр дә гариза ышанычлы зат тарафыннан бирелә икән, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе.

Һәлак булучының (үлученең) гаилә әгъзасы гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспортын (аны алмаштыра торган документны) күрсәтә.

Тапшырылган документларда хаталар (язу, басма хаталары) булган очракта, гаризада тиешле аңлатмалар бирелә.

5. Зыян күрүче гражданин яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат бер мәртәбә матди ярдәм түләү турында гаризаны шушы Тәртипкә 2 нче кушымтага туры китереп тапшыра.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе тарафыннан бирелгән, гражданинны зыян күрүче дип тану турында документ күчермәсе;

сәламәтлеккә китерелгән зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтеп, суд-медицина экспертизасы бәяләмәсе күчермәсе;

кредит оешмасында ачылган лицевой счет реквизитлары белән документ күчермәсе;

әгәр дә гариза ышанычлы зат тарафыннан бирелә икән, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе.

Зыян күрүче гражданин гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспортын (аны алмаштыручы документны) күрсәтә.

Тапшырылган документларда хаталар (язу, басма хаталары) булган очракта, гаризада тиешле аңлатмалар бирелә.

6. Документларның күчермәләре, әгәр дә алар нотариаль яктан таныкланмаган булса, чын нөсхәләрен күрсәтеп, берәр нөсхәдә тапшырыла һәм Министрлык яисә социаль яклау органы белгече тарафыннан таныклана.

Гариза һәм гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре Министрлыкка яисә социаль яклау органына почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

7. Министрлык яисә социаль яклау органы гаризаны һәм документларны тикшерә. Гаризаны гаризаларны теркәү журналында теркәү шушы Тәртипнең 4 яки 5 пунктларында күрсәтелгән барлык документларны тапшырганда гамәлгә ашырыла.

8. Һәлак булучының (үлученең) ике һәм аннан күбрәк гаилә әгъзасыннан гаризалар булганда бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм һәр гаилә әгъзасы өчен билгеләнгән күләменнән тигез өлешләрдә түләнә. Гаилә әгъзалары арасында бер мәртәбә матди ярдәм алу буенча ризасызлыклар булган очракта, бер мәртәбә матди ярдәм алар тарафыннан мондый ризасызлыклар тулысынча җайга салынганнан соң һәм бер мәртәбә матди ярдәм алучы (алучылар) билгеләнгәннән соң законнарда билгеләнгән тәртиптә түләнә.

Бер мәртәбә матди ярдәмнән өлеш алу хокукы булган гаилә әгъзасы Министрлыкка яисә социаль яклау органына ирекле рәвештә гариза тапшыру

юлы белән, бер мәртәбә матди ярдәм алуга хокукы булган гаиләнең бүтән әгъзасы файдасына аны алудан баш тартырга мөмкин.

9. Шушы Тәртипкә 3 нче, 4 нче кушымталарга туры китерелгән рәвештә бер мәртәбә матди ярдәм билгеләү турында карар, гаризаны барлык кирәкле документлары белән теркәгән датадан соң, Министрлык тарафыннан 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

10. Бер мәртәбә матди ярдәм һәлак булучының (үлученең) вафат булуы, гражданинның зыян күрүче дип танылган көненнән соң алты айдан да соңга калмыйча сорап мөрәҗәгать иткән очракта билгеләнә.

11. Бер мәртәбә матди ярдәм билгеләү турында кабул ителгән карарлар нигезендә Министрлык өч эш көне эчендә алучыларның исемлекләрен формалаштыру һәм финанслау өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына заявка җибәрә.

12. Бер мәртәбә матди ярдәм суммаларын алучыларның счетларына күчерү Министрлык тарафыннан күрсәтелгән максатларга акча чаралары күчкән көннән башлап биш эш көне эчендә башкарыла.

13. Тиешле түләүләрне түләп бетергәннән соң өч эш көне эчендә Министрлык Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәлак булучыларның (үлучеләрнең) гаилә әгъзаларына, шулай ук зыян күрүче гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү өчен бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуы турында хисап тапшыра.

2017 елның 2 июлендә
Татарстан Республикасының
Зәй районында булган
автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян
күргән гражданнарга бер
мәртәбә матди ярдәм күрсәтү
тәртибенә

1 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы
(_________________________________ районының
территориаль социаль яклау органы)
(кемнән)________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________
(түбәндәге адрес буенча теркәлгән).

_______________________________________________
паспорт: серия ___________ № _______________
кем тарафыннан бирелгән______________________
бирелү датасы__________________________________

ГАРИЗА

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасы Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) ________________________________________________
(һәлак булучының (үлүченең) фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_________________________________өчен миңа бер мәртәбә матди ярдәм түләүне сорыйм.

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасы Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булучының (үлүченең) бер мәртәбә матди ярдәмгә хокукы булган гаилә әгъзалары турындагы мәгълүматларны хәбәр итәм:

| № п/п | Гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне, ае, елы | Туганлык дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булучының (үлүченең) бер мәртәбә матди ярдәм алуга хокукы булган бүтән гаилә әгъзалары, шулай ук һәлак булучының (үлүченең) иждивениесендә торган затлар юк.

_______________________________________________________________________________
(тапшырылган документларда хаталар (язу, басма хаталары) булган очракта аңлатмалар)

_______________________________________________________________________________

Бер мәртәбә матди ярдәмне ____________________________________________________________
(кредит оешмасының аталышы һәм реквизитлары)

____________________________________________________кредит оешмасына күчерүне сорыйм.

Счет номеры:
________________________________________________________________________________

«___» _________ 2017 ел ___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

2017 елның 2 июлендә
Татарстан Республикасының
Зәй районында булган
автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян
күргән гражданнарга бер
мәртәбә матди ярдәм күрсәтү
тәртибенә

2 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (________________________________районының территориаль социаль яклау органы)
(кемнән)______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_____________________________________________
(түбәндәге адрес буенча теркәлгән):

_____________________________________________
паспорт: серия ___________ № ________________
кем тарафыннан бирелгән_____________________
бирелү датасы_________________________________

# ГАРИЗА

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күрүче буларак, миңа бер мәртәбә матди ярдәм түләүне сорыйм.

________________________________________________________________________________
(тапшырылган документларда хаталар (язу, басма хаталары) булган очракта аңлатмалар)

________________________________________________________________________________

Бер мәртәбә матди ярдәмне ___________________________________________________
(кредит оешмасының аталышы һәм реквизитлары)
__________________________________________кредит оешмасына күчерүне сорыйм.

Счет номеры:
__________________________________________________________________________

«___» _________ 2017 ел                    ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

2017 елның 2 июлендә Татарстан
Республикасының Зәй районында булган
автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән
гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм
күрсәтү тәртибенә

3 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган
автоһәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгәннәр арасында зыян күрүче
гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм билгеләү турында
карар

№________ «____» ________ 2017 ел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү турында” 2017 елның 02 июлендәге 455 номерлы карары нигезендә 2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданинга бер мәртәбә матди ярдәм билгеләргә

| Зыян күрүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсе | Түләү күләме (мең сум) |
|---|---|---|
| | | |

Министр урынбасары ________________ ______________________________________
(имза)

Баш бухгалтер ________________ ______________________________________
(имза)

Билгеләүне гамәлгә ашырдылар ____________ ______________________________________
(имза)

М.У.

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү тәртибенә

4 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булучыларның гаилә әгъзаларына бер мәртәбә матди ярдәм билгеләү турында карар

№_____ «____» ________ 2017 ел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү турында” 2017 елның 02 июлендәге 455 номерлы карары нигезендә 2017 елның 2 июлендә Татарстан Республикасының Зәй районында булган автоһәлакәт нәтиҗәсендә үлгән ____________________________________________
(һәлак булучының (үлүченең)Ф.И.А.)

гражданинның гаилә әгзасына (әгъзаларына) бер мәртәбә матди ярдәм билгеләргә.

| Гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Түләү күләме (мең сум) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Министр урынбасары _________________ ______________________________________
(имза)

Баш бухгалтер _________________ ______________________________________
(имза)

Билгеләүне гамәлгә ашырдылар ___________ __________________________________________
(имза)

М.У.